| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 сентябрь 2016ел № 5112

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге буенча торакның гомуми
мәйданының 1 квадрат метры өчен
бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Россия гражданнарына – һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак» илкүләм проектын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 санлы Карары белән расланган «2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында торак сатып алу (төзү) өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләренең 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 санлы Карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында торак сатып алу өчен яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пунктына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2016 елның икенче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы һәм 2016 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2016 елның 16 июнендәге 419/пр санлы Боерыгына туры китереп

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләр өчен торак сатып алуга яки шәхси торак йорт төзүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрына бәя нормативын 2016 елның өченче кварталына 34 389 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе